КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пункты территориясенең бер өлешендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 12 декабрь № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 12 декабрь уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:
торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда Лесная, Майская, Яшьләр урамнары буйлап юлларны карап тоту)

«Әйе» «Юк»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 12 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 12 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пункты территориясенен бер өлешендә гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты территориясенуң бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2025 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге юнәлтү белән килешәсе:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда Лесная, Майская, Яшьләр урамнары буйлап юлларны карап тоту)

ӘЙЕ ЮК».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Майская Горка авыл җирлеге сайтында, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов